Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Комыргуҗа авыл җирлеге Советы Карары

30 март 2021 ел — № 23

«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Советының «Комыргуҗа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 22 сентябрендәге 63 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2017 елның 29 декабрендәге № 463-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертүе нигезендә, Әтнә районы прокуратурасының 17.02.2021 ел, № 02-01-15/13-21 «Җирлек территориясендә җир эшләрен үткәрү тәртибен җайга салучы норматив-хокукый актны кабул итү турында" гы тәкъдимен карап һәм өйрәнеп Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 сентябрендәге 63 номерлы карары нигезендә расланган «Комыргуҗа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» гы карарына 1 нче номерлы кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы — Ф.Ф.Низамиев

(М.П.: Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Совет Комыргузинского сельского поселения Комыргуҗа авыл җирлеге Советы ИНН 1610000733)

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Комыргуҗа авыл җирлеге Советының
2021 елның 30 мартындагы 23 номерлы карарына
1 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Советының «Комыргуҗа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 22 сентябрендәге 63 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

Комыргуҗа авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 сентябрендәге 63 нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1. 2.1 пунктының 6 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:**

«территорияне төзекләндерү – муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән чаралар комплексын тормышка ашыру, гражданнарның яшәү шартларын яхшырту, муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын яхшырту, торак пунктларның территорияләрен һәм мондый территорияләрдә урнашкан объектларны, шул исәптән гомуми кулланыштагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, якын-тирә территорияләрне карап тоту буенча эшчәнлек;”

**2.2.1 пунктының 44 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:**

«якын-тирә территория - гомуми файдаланудагы территория, бина, төзелмә, корылма, җир кишәрлеге янәшәсендәге мондый җир кишәрлеге һәм чикләре Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртип нигезендә муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән очракта, барлыкка килгән территория»

**3.2.1 пунктының соңгы абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:**

"төзекләндерү элементлары - декоратив, техник, планировка, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, төрле җиһазлар һәм бизәү элементлары, шул исәптән биналар, төзелмәләр, корылмалар, кече архитектура формалары, капиталь булмаган стационар булмаган төзелмәләр һәм корылмалар, мәгълүмат щитлары һәм күрсәткечләр, территорияне төзекләндерүнең состав өлешләре буларак кулланыла торган»

**4. 11 статьяның 11.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:**

«11.1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан бирелгән язма рөхсәт (җир асты коммуникацияләрен салу, реконструкцияләү һәм ремонтлау, субай һәм шпунтны сугып кертү, электр тапшыру, элемтә, ут баганалары урнаштыру (алмаштыру), грунтны планлаштыру, инженерлык эзләнүләре вакытында эшләр һәм башка эшләр) булганда гына башкарыла.»